Татар теле , 7 нче сыйныф.

Тема: **Аерымланган сәбәп һәм аерымланган максат хәлләре.**

Максат:
1) аерымланган сәбәп һәм аерымланган максат хәлләренең белдерелү үзенчәлекләрен аңларга ярдәм итү.
2) Төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен үстерү;
3) Игътибарлылык, бер-береңә хөрмәт хисләре тәрбияләү.

Материал : дәреслек
Дәрес тибы – УМ кую һәм чишү.

Дәрес барышы:
**I. Мотивлаштыру-ориентлашу.** **ХАЙ ФАЙВ**-тынычлану сигналын кулану.
1. а) психологик уңай халәт тудыру;
ә) белемнәрне актуальләштерү.
- Без синтаксисның кайсы үлеген өйрәнәбез? (җөмлә кисәкләрен)
Сез хәзер ***КУИЗ-КУИЗ-ТРЕЙД (опроси-опроси-обменяйся)*** структурасы ярдәмендә бер – берегезнең белемнәрен тикшерерсез.
- Моның өчен сезгә карточкалар ясарга кирәк булачак.
-Хәзер беренче номерлы партнерлар ак бит алалар, битне уртага бүләләр. Яртысын иң баш партнерына бирәләр һәм тагын уртага битне бүлергә тиеш буласыз. Битнең берсен йөзгә йөз партнерга бирәсез.
Битнең астын 4\1 өлешен бөкләргә кирәк була.(Күрсәтелә).
-Битнең күренә торган өлешенә сез иң яхшы дип саналган соравыгызны язасыз,ә күренми торган өлешенә соравыгызга җавабы языла.
- Моны эшләү өчен сезгә 2 минут вакыт бирелә. Вакыт башланды (Таймер куела)
- вакыт бетте
- Хәзер сез торасыз, кулыгызны күтәрәсез, якында булган иптәшегез янына барасыз һәм соравыгызны бирәсез, иптәшегез сорауга җавап бирергә тиеш. Иптәшегез сорауга җавап бирә алмаса сез аңа булышасыз. Дөрес җавап ишеткәннән соң иптәшегезне мактыйсыз һәм аның соравын тыңлап җавап бирәсез. Бергә кабатлыйбыз “Молодец, рәхмәт миңа синең белән эшләргә бик рәхәт булды”
- Без нинди җөмлә кисәкләрен өйрәнәбез?
-Нинди хәлләр аерымланган хәлләр дип атала? Ничә шарт үтәлергә тиеш?
-Кайсы хәлләр аерымлана? Кайсылары аерымланмый? –
**ФИНК-РАЙТ-РАУНД РОБИН** *( Укучылар уйлагач, җавапны кәгазьгә язалар. Укучылар чират буенча, җавапларны кәгазьдән укыйлар_*
Б) Җөмләдәге хәлләрнең төркемчәсен билгеләү.
-Үткән дәрестә без нинди уку мәсьәләсе куйдык?
К.ж.: *Без үткән дәрестә аерымланган вакыт һәм аерымланган рәвеш хәлләре турында төшенчә алдык.* (Модельләр әйтелә)
2. Ярым иҗади һәм иҗади өй эшләрен тикшерү:
а) я 286 нчы күнегү; ә) и 287 нче күнегү.

**3. УМ кую ситуациясе. 47 нче бирем**. Җөмләләрне күчереп язарга, аерымланган хәлләрнең асларына сызарга һәм дәрескә УМ билгеләргә.
К.җ.: 1. *Бер атнадан бирле йокламаганлыктан – ни сәбәпле*? *аерымланган сәбәп хәле.*
*2. Куркак булмас өчен – нинди максат белән? (ни өчен?) аерымланган максат хәле. Димәк, без бүген аерымланган сәбәп һәм аерымланган максат хәлләре турында өйрәнербез.*
Тактага һәм дәфтәрләргә тема языла.
**II. УМ адымлап (өлешләп) чишү . МЭНЭДЖ МЭТ**
1. 288 нче күнегү. Аерымланган сәбәп хәлләрен үзләре ачыклаган сүзләре белән язып алырга. Ю.к. с.ф. б.
Ю.к. с.ф.
*К.җ.: 2.* ***Арыганга күрә*** *ял иттек – ни сәбәпле? 3. Зур коңгырт эшләпәсен басып* ***кигәнгә***
*Ч.к.с.ф.*
*күзгә ташланмый – нигә? 4. Әти тирәсендә чуалып* ***үскәнлектән*** *киттеләр – нилектән?*
*ис.ф. ис.ф. б.с.*
*Артык күп* ***уку һәм язу аркасында*** *әчетә башлаган иде – нәрсә аркасында?*
2. 289 нчы күнегү. Җөмләләрне күчереп язарга, аерымланган максат хәлләренең асларына сызарга һәм белдерелү үзенчәлекләрен өсләрендә күрсәтергә.
К.җ.: *к.з. с.ф. б. б.ф. я.ф.*
*1. Җир йөзен татлы йокысыннан* ***уятыр өчен****. 2. …,* ***аунап ятмасын дип,…***
*3. Үзебезнең*
*ис.ф. ис.ф. б. к.з. с.ф. б.*
*ялгышуыбызны аңлау, аны күтәрә* ***белү өчен****. 4…., якты бәхетебезне* ***бирмәс өчен*** *фашист кулына.*
3. Модельләштерү. 290 нчы күнегү. Аерымланган сәбәп һәм аерымланган максат хәлләренең белдерелү үзенчәлекләре турында модель төзергә.
4. 291 нче күнегү. Дөрес җавапны аерып язарга: а) аерымланган сәбәп хәле булган җөмлә;
ә) аерымланган максат хәле булган җөмлә.
К.җ.: *1. ә; 2. ә; 3. а; 4. ә; 5. а; 6. ә..*
**III. Рефлексия, бәяләү.**
1.- Дәрескә нинди УМ куйган идек?Ниләр башкардык?

**ТАЙМД РАУНД РОБИН** . Һәр укучы 30 секунд эчендә Бүген дәрестә үзенә нинди яңалык ачканын сөйли. Һәр өстәлдән 1-2 укучыдан сорыйм.

2. Дәрескә гомуми бәя.
3. Өй эше:
а) м 292 нче күнегү;
ә) я 293 нче күнегү;
б) и 294 нче күнегү.